КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 24 ноябрь г.Казань № 1056

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2023 елларга Татарстан Республикасының торак-коммуналь хуҗалыгын, сәнәгать һәм башка оешмаларын газлаштыру буенча төбәк программасын раслау турында» 2019 ел, 30 декабрь, 1265 нче карары белән расланган 2019 – 2023 елларга Татарстан Республикасының торак-коммуналь хуҗалыгын, сәнәгать һәм башка оешмаларын газлаштыру буенча төбәк программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2023 елларга Татарстан Республикасының торак-коммуналь хуҗалыгын, сәнәгать һәм башка оешмаларын газлаштыру буенча төбәк программасын раслау турында» 2019 ел, 30 декабрь, 1265 нче карары белән расланган 2019 – 2023 елларга Татарстан Республикасының торак-коммуналь хуҗалыгын, сәнәгать һәм башка оешмаларын газлаштыру буенча төбәк программасына, аны бу карарга теркәлгән яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә.

2. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетына 2021 елга «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең газ бүлү челтәрләре буенча газ транспортлау буенча хезмәт күрсәтүләр тарифларына махсус өстәмә билгеләгәндә исәп-хисапларда 2021 елга Татарстан Республикасын газлаштыру чаралары планының төп бүлеген файдаланырга.

3. «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә 2022 елның 1 мартына кадәр 2021 елга Татарстан Республикасын газлаштыру чаралары планы үтәлеше турындагы хисапны Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына кертүне тәкъдим итәргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин